ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.07.2023 ел. Баулы шәһәре №141

2023 елда Баулы муниципаль районы
сулыкларында кешеләрнең иминлеген
тәэмин итү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»,1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләре» карары белән Россия Федерациясе Су кодексы, Федераль законнары нигезендә Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан сулыкларда кешеләрнең тормышын саклау һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен (алга таба – кагыйдәләр) кулланырга һәм үтәргә.

2. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарындагы Территориаль бүлеге белән килешү буенча Баулы шәһәренең ачык бассейнын халыкның күпләп ял итү һәм коену өчен оештырылган урыны итеп билгеләргә һәм аны күпләп ял итү һәм коену өчен кулланырга.

3. Баулы муниципаль районы һәм Баулы шәһәре территориясендә оештырылмаган (билгеләнмәгән) урыннарда халыкны су коенудан тыю.

4. Авыл җирлекләре башлыкларына:

- авыл җирлекләре территориясендә су коену һәм күпләп ял итү өчен оештырылган урыннарны билгеләргә, пляжларны Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләргә туры китереп төзекләндерергә;

- оештырылмаган (билгеләнмәгән) урыннарда халыкны су коенудан тыю.

5. «Баулы-ГорСервис» МКП-сенә Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясы, 27 статьясы һәм Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләргә ярашлы рәвештә Баулы шәһәренең ачык бассейнында пляж ясауны тәкъдим итәргә.

6. Баулы муниципаль районы территориясендәге сулыкларны (буаларны, ачык бассейннарны, пляж зоналарын) куркынычсызлыкка тикшерү үткәрү буенча комиссиянең кушымта составын расларга (алга таба - комиссия).

7. Комиссиягә Баулы муниципаль районының сулыкларын (сулыкларын, ачык бассейннарын, пляж зоналарын) системалы рәвештә тикшерергә.

8. Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге начальнигына рөхсәт ителгән пляж зоналарында хокук тәртибен саклауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

9. «Татмедиа» АҖ «Баулы-Информ» филиалына халыкка елгалар һәм сулыклар янында үз-үзләрен тоту кагыйдәләре, шулай ук Баулы муниципаль районы территориясендә су коену өчен җиһазландырылмаган, куркыныч һәм тыелган урыннар турында мәгълүмат бирүне оештырырга тәкъдим итәргә.

10. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ начальнигына җәйге чорда балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында йөзү күнекмәләрен, тәртипнең гомуми кагыйдәләрен, суда экстремаль хәлдә эш итү буенча күрсәткеч чаралар оештырырга.

11. «Баулы-ГорСервис» МКП-сенә суда зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү өчен су коену сезоны вакытында Баулы шәһәренең ачык бассейны территориясендә дежурлык оештырырга тәкъдим итәргә.

12. Баулы муниципаль районы сулыкларындагы эпидемиологик хәлне контрольдә тотуны Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарындагы Территориаль бүлеге начальнигына тәкъдим итәргә.

13. База һәм ял лагерьлары территориясендә су коену өчен ясалма сулыклары булган оешма җитәкчеләренә, Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә, су объектларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар оештырырга тәкъдим итәргә.

14. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

15. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Д.Л. Бакиров

2023 елның 5 июлендәге
141 номерлы
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты
карары белән
РАСЛАНГАН

Баулы муниципаль районы территориясендәге сулыкларны (буаларны, ачык бассейннарны, пляж зоналарын) куркынычсызлык өчен тикшерү комиссиясе составы

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;
2. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары;
3. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары;

4. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарындагы территориаль бүлегенең әйдәп баручы белгече (килешү буенча);

5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча);

6. «Баулы үзәк район хастаханәсе» баш табибы (килешү буенча);

7. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе;

8. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ начальнигы;

9. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы.